КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 30 декабрь г.Казань № 1471

2022 елда Казан шәһәренең «12 нче шәһәр клиник хастаханәсе» акционерлык җәмгыятенә учреждениедә вакытлыча (ковид) йогышлы авырулар госпитале ачылу белән бәйле алынмаган керемнәрне каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән 2022 елда Казан шәһәренең «12 нче шәһәр клиник хастаханәсе» акционерлык җәмгыятенә учреждениедә вакытлыча (ковид) йогышлы авырулар госпитале ачылу белән бәйле алынмаган керемнәрне каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 15 июнь, 557 нче карары белән расланды

2022 елда Казан шәһәренең «12 нче шәһәр клиник хастаханәсе» акционерлык җәмгыятенә учреждениедә вакытлыча (ковид) йогышлы авырулар госпитале ачылу белән бәйле алынмаган керемнәрне каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчалары исәбеннән 2022 елда Казан шәһәренең «12 нче шәһәр клиник хастаханәсе» акционерлык җәмгыятенә (алга таба - акционерлык җәмгыяте) учреждениедә вакытлыча (ковид) йогышлы авырулар госпитале ачылу белән бәйле алынмаган керемнәрне каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели (алга таба - Субсидия).

2. Субсидия бирүгә юнәлтелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

3. Акчаны тоту Министрлык тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счет аша гамәлгә ашырыла.

4. Субсидия Министрлык тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджет чараларын алучы буларак Министрлыкка әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

5. Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталындагы «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

6. Субсидия акционерлык җәмгыятенең Субсидия бирү турындагы килешү (алга таба – Килешү) төзелгән айга кадәрге айның беренче көненә түбәндәге таләпләргә туры килүе шарты белән бирелә:

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмау. 2022 елда салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән, 300 мең сумнан артмаган йөкләмәсе булырга мөмкин;

2022 елда Россия Федерациясенә, Россия Федерациясе гражданнарына яки Россия юридик затларына карата дусларча булмаган гамәлләр кылучы чит ил

дәүләтләре тарафыннан сәяси яки икътисадый санкцияләр кертелү аркасында товарлар кайтарту, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү турында төзелгән дәүләт (муниципаль) контрактларын үтәүдән баш тартуга һәм (яки) чит ил дәүләтләре, чит ил дәүләтләренең дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлары һәм (яки) дәүләт (дәүләтара) учреждениеләре яки дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлар тарафыннан чикләү характерындагы чаралар кертелүгә бәйле рәвештә, намуссыз тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) реестрында булмаска;

үзгәртеп оештыру (акционерлык җәмгыяте булган юридик затка кушу, башка юридик зат рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәү, сайлап алуда катнашучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмау;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән акционерлык җәмгыяте җитәкчесе, акционерлык җәмгыятенең коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер акционерлык җәмгыяте башкара торган башкарма орган функциясен үтәүче зат яки акционерлык җәмгыятенең баш хисапчысы турында мәгълүматлар булмау;

чит ил юридик заты, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы расланган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит илләр юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артмаган Россия юридик заты булмау;

Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә бу Тәртипнең 1 пункты белән билгеләнгән максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмау;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый.

7. Акционерлык җәмгыятенә бирелә торган Субсидия күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

8. Субсидия бирелә торган кайтарылмаган керемнәрнең юнәлешләре булып вакытлыча (ковид) йогышлы авырулар госпитале ачылу белән бәйле алынмаган керемнәр тора.

9. Субсидия алу өчен акционерлык җәмгыяте Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

ирекле рәвештә язылган һәм акционерлык җәмгыяте җитәкчесе яки башка вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган Субсидия бирүгә заявка (алга таба – Заявка), Субсидия исәбе белән;

акционерлык җәмгыяте җитәкчесе яки башка вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган, акционерлык җәмгыятенең бу Тәртипне6 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турындагы мәгълүматны үз эченә алган хат;

вәкаләтле зат леге пунктның икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән документларны имзалаганда вәкаләтле затның (әгәр мондый затның бердәм башкарма орган булмаса) вәкаләтләрен раслый торган документ;

вакытлыча (ковид) йогышлы авырулар госпитале ачылуны раслый торган документларның күчермәләрен;

вакытлыча (ковид) йогышлы авырулар госпитале ачылудан башкарылган чыгымнарны һәм алынмаган керемнәрне раслаучы документларның күчермәләре.

10. Акционерлык җәмгыяте үз инициативасы белән түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсен йә Юридик затларның бердәм дәүләт реестры кәгазе күчермәсен;

юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә күчермәсе;

Килешү төзелгән айдан алдагы айның беренче числосына яисә 2022 елда бирелгән салым органының килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәрге айның беренче көненә карата бирелгән, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмә булмавын раслый торган белешмә кәгазе яки салым органының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән, 300 мең сум күләменнән артмаган йөкләмә булуын раслый торган оешмалар һәм индивидуаль эшмәкәрләр салымнары, җыемнары, иминият кертемнәре, пенялары, штрафлары, процентлары буенча исәп-хисаплар торышы турында белешмә кәгазе.

11. Акционерлык җәмгыяте әлеге Тәртипнең 10 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, Министрлык әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

12. Министрлык Заявканы теркәлгән документлары белән кабул итүне һәм кергән көнендә теркәүне гамәлгә ашыра.

13. Министрлык Аакционерлык җәмгыятеннән Заявка һәм әлеге Тәртипнең 9 һәм 10 пунктларында күрсәтелгән документларны алган көннән өч эш көненнән дә артмаган вакыт эчендә аларның комплектлыгын тикшерә һәм Субсидия бирү турында йә Субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, Министрлык әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән вакыт эчендә акционерлык җәмгыятенә Субсидия бирүдән баш тарту турында язма хәбәрнамә җибәрә.

14. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

акционерлык җәмгыяте бу Тәртипнең 9 пунктында каралган документларның тапшырылмау (тулы күләмдә тапшырылмавы);

акционерлык җәмгыяте тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртипнең 9 пунктында каралган таләпләргә туры килмәве;

акционерлык җәмгыяте тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау фактын билгеләү.

15. Субсидия бирү Министрлык һәм акционерлык җәмгыяте арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма буенча төзелә торган Килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

Килешүдә Субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, исәпләү тәртибе, Субсидияне акционерлык җәмгыяте тарафыннан кире кайтару очраклары һәм тәртибе, Субсидия бирү тәмамлануның төгәл датасы нәтиҗәсенең ахыргы мәгънәсе (нәтиҗәләрнең конкрет микъдари характеристикасы), акционерлые җәмгыяте тарафыннан өстәмә хисаплылык бирү сроклары һәм рәвешләре, әлеге Тәртипнең һәм төзелә торган Килешүнең шартларын үтәү турындагы нигезләмәләр, Килешү шартларын бозган өчен җаваплылык, акционерлык җәмгыяте белән Килешүнең яңа шартларын килештерү шарты, Министрлык тарафыннан күрсәтелгән бюджет йөкләмәләренең элек җиткерелгән лимитлары кимегән очракта, Килешүнең яңа шартлары буенча килешүне өзү шарты, әлеге Субсидия бирү Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән бюджет йөкләмәләре вакытыннан алда китерелгән лимитны киметкән очракта ( 2022 елда билгеләнгән күләмдә һәм яңа шартларны килештерү).

16. Субсидия бирү нәтиҗәсе - 2022 елның 31 декабренә торышы буенча акционерлык җәмгыяте хезмәткәрләренә түләнгән файдаланылмаган отпуск өчен компенсация күләме.

2022 елда Субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә Килешүдә билгеләгән срокларда ирешү мөмкинлеге булмауга китерә торган шартлар барлыкка килгән очракта, Министрлык, акционерлык җәмгыяте белән килештереп, Субсидия күләмен үзгәртмичә, Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү срокларын (әмма иң күбе 24 айга) озайту өлешендә Килешүгә үзгәрешләр кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Субсидия күләмен үзгәртмичә, субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү мөмкинлеге булмаган очракта, Министрлык субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткечен киметү турында карар кабул итәргә хокуклы.

17. Министрлык Субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча Россия Федерациясе Үзәк банкы яисә кредит оешмалары учреждениеләрендә ачылган акционерлык җәмгыятенең исәп-хисап яисә корреспондентлык счетына акчалар күчерүне гамәлгә ашыра.

18. Акционерлык җәмгыяте Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгы боерыгы белән расланган килешүнең бертип формасы буенча, хисап аеннан соң килүче бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча, Субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе турында хисап тапшыра.

19. Министрлык акционерлык җәмгыятенең Субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

20. Акционерлык җәмгыяте тарафыннан Субсидия бирү шартлары бозылган очракта, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган, шулай ук нәтиҗәгә ирешү күрсәткече җитмәгән очракта, Субсидия яисә аның өлеше кире кайтарылырга тиеш.

21. Министрлык әлеге Тәртипнең 20 пунктында күрсәтелгән фактлар билгеләнгән көннән 30 календарь көн эчендә акционерлык җәмгыятенә Субсидияне

яки аның бер өлешен кире кайтару кирәклеге турында язма хәбәрнамә җибәрә, анда Субсидияне кире кайтару өчен нигез булып торган сәбәпләрне һәм акча күчерү өчен реквизитларны күрсәтә.

Акционерлык җәмгыяте Субсидияне яки аның бер өлешен кире кайтару кирәклеге турында язма хәбәрнамә алган көннән 30 календарь көн эчендә Субсидия акчасын кире кайтарырга тиеш.

Акционерлык җәмгыяте Субсидия акчасын ирекле тәртиптә кире кайтарырга баш тартса, Субсидия акчасы Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә түләтелә.

22. Акционерлык җәмгыяте тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык акционерлык җәмгыятенең вазыйфаи затларына йөкләнә.

23. Субсидияне файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.